Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № Х-14**

Балык Бистәсе штп. 2016 елның 23 апреле

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына керә торган хәбәрнамәләрне карау буенча эш нәтиҗәләре турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппараты җитәкчесе Р.Д. Исмәгыйлевның Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районындагы «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына керә торган мөрәҗәгатьләрне (хәбәрнамәләрне) карау эше нәтиҗәләре турында мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына керә торган мөрәҗәгатьләрне карау эше нәтиҗәләре турында мәгълүматны игътибарга алырга.

2.Вазыйфаи затларга (урындагы кешеләргә) тәкъдим итәргә:

- Татарстан Республикасының «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына керә торган мөрәҗәгатьләрне карау эшен дәвам итәргә;

-массакүләм мәгълүмат чараларында «Халык контроле» Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системасы эшен актив яктыртырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г.Вәлиев